СОВЕТ
НОВОКЫРЛАЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д. 3, с.Новый Кырлай,
Арский муниципальный район, 422035

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КЫРЛАЙ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Үзәк урам, 3 йорт, Яңа Кырлай авылы,
Арча муниципаль районы, 422035

Тел. (84366)56-7-32, факс (84366)56-7-34. E-mail: Nkrl.Ars@tatar.ru

# КАРАР

15.06.2020 № 101

## Өченче чакырылыш Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Советына депутатлар сайлаулары билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясы, 2007 елның 7 маендагы 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 105 статьясының 1 өлеше, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Уставының 13 статьясы нигезендә Яңа Кырлай авыл җирлеге Советы **карар бирде**:

1. Өченче чакырылыш Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Советына депутатлар сайлауларын 2020 елның 13 сентябренә билгеләргә.
2. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң биш көннән дә соңга калмыйча “Арча хәбәрләре” (“Арский вестник”) район газетасында, Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы рәсми сайтында (https://arsk.tatarstan.ru/) һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда: Яңа Кырлай авылы, Үзәк урам, 3 нче йорт; Өчиле авылы, Тукай урамы, 73 нче йорт адреслары буенча мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Яңа Кырлай авыл җирлеге башлыгы Г.Г.Сәфәров